# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан ССР Президентының намусын
һәм абруен яклау турында

Татарстан Республикасы дәүләт җитәкчесе буларак, Татарстан ССР Президентының намусына һәм абруена кагылмауның зарурлыгын танып, Татарстан ССР Югары Советы БИЛГЕЛИ:

1 маддә. Татарстан ССР Президентын халык алдында мәсхәрәләгән яисә аңа яла яккан өчен

өч мең сум күләмендәге штраф рәвешендә җәза билгеләнә.

Матбугат яисә массакүләм мәгълүмат чараларын кулланып башкарылган шул ук гамәлләр өчен

суд тәртибендә биш мең сум күләмендә штраф һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тиражын конфискацияләү рәвешендә җәза билгеләнә.

2 маддә. Татарстан ССР Президентын мәсхәрәләүче яисә аңа яла ягучы материал бастырып чыгарган массакүләм мәгълүмат чарасына суд карары буенча егерме мең сумга кадәр штраф салына һәм массакүләм мәгълүмат чараларының тиражы конфискацияләнә.

Татарстан ССР Президентын мәсхәрәләүче яисә аңа яла ягучы материалны кабат тараткан массакүләм мәгълүмат чарасының эшчәнлеге суд карары нигезендә туктатылырга мөмкин.

Татарстан ССР Югары Советы
Рәисенең беренче урынбасары Р.Шәмгунов